ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Теньковский авыл җирлегенең Тукай авылында 2024 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында

2023 елның 14 ноябре № 5

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел, №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Теньковский авыл җирлегенең Тукай авылында гражданнар җыены:

1.2024 елда Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Теньковский авыл җирлеге Тукай авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, 300,00 (өч йөз) сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү:

- җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту, торак пункт чикләрендә (шул исәптән вак ташлар сатып алу, ташу, салу, юлларны грейдировкалау, юлларны кышкы тоту, ягулык-майлау материаллары, трактор өчен запас частьләр сатып алу);

- тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны (шул исәптән лампалар, энергия саклаучы яктырткычлар, электр товарлары сатып алу)ремонтлау;

торак пункт территориясен төзекләндерү (шул исәптән җәйге-көзге чорда чүп үләннәрен кисү)

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту, торак пункт чикләрендә (шул исәптән вак ташлар сатып алу, ташу, салу, юлларны грейдировкалау, юлларны кышкы тоту, ягулык-майлау материаллары, трактор өчен запас частьләр сатып алу);

- тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны (шул исәптән лампалар, энергия саклаучы яктырткычлар, электр товарлары сатып алу) ремонтлау;

торак пункт территориясен төзекләндерү (шул исәптән җәйге-көзге чорда чүп үләннәрен кисү)

3. Әлеге карарны адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә:

- Татарстан Республикасы, Кама Тамагы районы, Тукай авылы, Мичурин урамы, 15 нче йорт; шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматларының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,

Татарстан Республикасы Кама Тамагы

муниципаль районы Теньковский авыл җирлеге башлыгы: И. А. Зиновьев